**СОВЕТ КАЗАКЛАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422722, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Казаклар, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЗАКЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422722, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Казаклар авылы, Совет урамы, 5

Тел./факс 8(84365) 63-4-30, e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от «21» сентября 2020 г. № 1

**Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, 44 статьясындагы 2 өлеше нигезендә һәм 2020 елның 21 сентябрендәге 2 номерлы хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы

**КАРАР:**

1. "Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга һәм 1 нче Казаклар бермандатлы сайлау округы депутаты, Казаклар авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы рәисе итеп Идрисов Радик Хафиз улын сайларга.
2. Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына керешү көне дип Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көн дип санарга.
3. «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Казаклар авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Идрисов Радик Хафиз улын Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп кую турында.
4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ Фәрит Мөхәммәтшин "Бердәм Россия" Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге сәяси советы утырышын уздырды http://pravo.tatarstan.ru/.

Рәислек итүче Р.Х.Идрисов